СОВЕТ УСАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Первомайская, д.4, с. Усали, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422174

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ҮСӘЛИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Беренче май ур., 4 нче йорт, Үсәли авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422174

тел.(факс): (85563) 2-74-10; e-mail: Usal.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение | Карар
№ 2-44 | от 15.07.2019г.

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге Советының 17.09.2018 ел, 4-35 санлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 1 маендагы 87-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге Советының 2018 елның 17 сентябрендәге 4-35 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыеннарын әзерләү һәм уткәрү тәртибе турындагы» Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Әлеге статьяда каралган гражданнар җыены торак пункт яки җирлек халкының сайлау хокукына ия булган яртысыннан артык кеше катнашында хокуклы. Әгәр торак пунктта әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең яртысыннан артыгы бер үк вакытта сайлау хокукына ия булган булса, авыл җирлеге Уставы нигезендә гражданнар җыены гражданнар җыенын үткәрү турында Карар кабул ителгәннән соң бер айдан артмаган вакытка этаплап үткәрелә. Шул ук вакытта элегрәк гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүнең алдагы этапларында катнашмый. Гражданнар җыены карары әгәр аның өчен халык җыенында катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.»;

1.2. 1.6 пунктының 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-авыллар арасындагы территорияләрдә урнашкан торак пунктта яңа төзелгән җирлек булдыру турында, шулай ук яңа төзелгән җирлектә, әгәр дә аның

сайлау хокукына ия кешеләре саны 300 дән артмаса, яңа төзелгән җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча халык инициативасын тәкъдим итү максатларында;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы авыл җирлеге стендларында урнаштырырга, Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Усали авыл җирлеге башлыгы А.И.Зиатдиновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Усали авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе А.И.Зиатдинов